Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

26 июль 2019 ел №307

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Рафаэль Төхвәтуллин исемендәге премияне бирү турындагы Нигезләмә хакында»гы 2009 елның 21 маендагы №324 карарына үзгәрешләр кертү турында

Хокукый мониторинг тәртибендә Әлмәт шәһәре прокуратурасының 2019 елның 25 июнендәге № 02-01-3/2019 таләпләрен карап тикшергәннән соң,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Рафаэль Төхвәтуллин исемендәге премияне бирү турындагы Нигезләмә хакында» гы 2009 елның 21 маендагы №324 карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2012 елның 30 маендагы №199, 2013 елның 7 февралендәге №280, 2013 елның 19 апрелендәге №301, 2016 елның 29 апрелендәге №69 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «Комиссия вәкаләтләре» 6 нчы бүлегенең 1 нче кушымтасындагы 7 нче абзацта «, кагыйдә буларак,» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Салахов И.Р.).

Муниципаль район
башлыгы урынбасары А.А. Зимин